**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4111**
**21.08.2020**

Чираттагы елга эчке муниципаль финанс контроленең контроль чараларын үткәрү планының типовой формасын раслау турында

«Дәүләт (муниципаль) финанс контролен, эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын камилләштерү өлешендә Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 26 июлендәге 199-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 27 февралендәге 208 номерлы карары белән расланган «Тикшерүләр, ревизияләр һәм тикшеренүләрне планлаштыру» эчке дәүләт (муниципаль) финанс контроле федераль стандартының 2 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Чираттагы елга эчке муниципаль финанс контроленең контроль чараларын үткәрү планының типовой формасын кушымтада каралганча расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2018 елның 27 апрелендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган һәм «Челнинские известия» газетасының 2018 елның 20 июнендәге 43 нче санында, 2018 елның 27 июнендәге 45 нче санында басылып чыккан «Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2018 елның 25 апрелендәге 2305 номерлы Башкарма комитет карары;

2) 2019 елның 20 маенда Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган һәм 2019 елның 24 маенда «Челнинские известия» газетасының 36 нчы санында басылып чыккан «Башкарма комитетның 2018 елның 25 апрелендәге 2305 номерлы карары белән расланган эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 маендагы 2519 номерлы Башкарма комитет карары;

3) 2019 елның 18 декабрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган һәм 2019 елның 20 декабрендә «Челнинские известия» газетасының 94 нче санында басылып чыккан «Башкарма комитетның 2018 елның 25 апрелендәге 2305 номерлы карары белән расланган эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ

регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 13 декабрендәге 6495 номерлы Башкарма комитет карары;

4) 2020 елның 15 маенда Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган һәм 2020 елның 15 маенда «Челнинские известия» газетасының 35 нче санында басылып чыккан «Башкарма комитетның 2018 елның 25 апрелендәге 2305 номерлы карары белән расланган эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 маендагы 2153 номерлы Башкарма комитет карары;

5) 2020 елның 27 маенда Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган һәм 2020 елның 27 маенда «Челнинские известия» газетасының 38 нче санында басылып чыккан «Башкарма комитетның аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 19 маендагы 2315 номерлы Башкарма комитет карарының 1 пункты.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Г.Г. Хамаевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 21 августындагы
4111 номерлы карарына
кушымта

Расланды:
Башкарма комитет
Җитәкчесе урынбасары,
финанс идарәсе башлыгы тарафыннан
_________________________________
(имза, имзаның расшифровкасы - Ф.И.А.и.)
«___» _____________ 20_._ ел

20_____ елга эчке муниципаль финанс контроленең контроль чараларын үткәрү планы

| Эчке муниципаль финанс контроле объектының яисә һәр контроль чарасы буенча контроль объектлары төркеменең исеме | Салым түләүченең идентификация номеры | Контроль чараның темасы | Тикшерү үткәрүгә нигез | | Тикшерелә торган чор | Контроль чара үткәрелә башлау чоры (датасы) | Контроль чараны үткәрү срогы (эш көннәрендә) | Контроль чараны үткәрү формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | соңгы тикшерү тәмамлану датасы | юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан эшчәнлек башлау датасы | | | | |
| | | | | | | | | |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева